КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 декабрь г.Казань № 1104

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясен төзү турында» 2006 ел, 17 апрель, 183 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясен төзү турында» 2006 ел, 17 апрель, 183 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 июнь, 260 нчы; 2012 ел, 22 сентябрь, 791 нче, 2012 ел, 24 октябрь, 903 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясе турында нигезләмәдә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясе (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының, шулай ук, аларның ведомствога каравына, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, оешмаларның гамәлләрен килештерүне тәэмин итүче даими эшләүче координацияләү органы була.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый

актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасының башка муниципаль хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.»;

4 пунктта:

дүртенче абзацка «үзара хезмәттәшлек» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «учреждениеләргә» сүзен «оешмаларына» сүзенә алмаштырырга;

сигезенче абзацка «ЮНЕСКО компетенциясе чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта:

икенче абзацка «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар һәм вазыйфаи затлар» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацка «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертә.»;

6 пунктта «карар белән» сүзләрен «карар белән» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Комиссия турында һәм» сүзләрен «Комиссия турында» сүзләренә алмаштырырга, «составы» сүзеннән соң «һәм бурычлары» сүзләрен өстәргә;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Комиссия Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасарлары, Комиссия башкарма секретаре һәм әгъзалары составында формалаша.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесесе Комиссия рәисе булып тора.

Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Комиссия утырышларында рәислек итә, эш төркемнәре составларын раслый.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Комиссия карарлары Комиссиянең утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм алар утырышта рәислек итүче һәм комиссиянең башкарма секретаре кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә, а кирәк булганда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 05 декабрь, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты -

Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре проектлары рәвешендә гамәлгә ашырыла. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.»;

Әлеге карар белән расланган ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин